Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары

КАРАР

**5 ноябрь 2024 нче ел** **№2**

«Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлегенең
Кызыл Тау авылында
гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. 2024 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең Кызыл Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: “Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эш төрләренә тотуга ризамы”

**1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

– торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (туфракны күтәрү, вак таш салу, вак таш сатып алу, юлларны җәен һәм кышын карап тору(кардан чистарту)-ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

**2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү:(Кызыл Тау авылы чишмәсен төзекләндерү)

« ӘЙЕ» “ЮК".

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин